ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2017 Казан ш. № 10-16/кс

Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында "Казан вертолет заводы" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга тарифлар билгеләү хакында

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында "Казан вертолет заводы" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. "Казан вертолет заводы" халыкка ачык акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.06.2017 ел № 10-16/кс карарына
кушымта

## Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында "Казан вертолет заводы" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган кайнар суга тарифлар

| № п/п | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | |
|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал |
| | | Карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | Карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр |
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | "Казан вертолет заводы" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 18,84 | 1501,07 |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 15,97 | 1272,09 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге